| ГЛАВА<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2019 г. Агрыз № 36

“Тирсә авылы Восточный тыкрыгы, 3,5,7,9,11,13нче торак йортларга газүткәргечләрне тармакландыру” линия объектын межалау һәм планлаштыру проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 46нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган «ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»гы Нигезләмә нигезендә (“ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 28 декабрендәге 33-2нче санлы үзгәрешләр белән) карар бирәм:

1. “Тирсә авылы Восточный тыкрыгы, 3,5,7,9,11,13нче торак йортларга газүткәргечләрне тармакландыру” линия объектын межалау һәм планлаштыру проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләү.

Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләү.

2. Билгеләү:

2.1. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру вакыты – 2019 елның 7 маеннан 2019 елның 7 июненә кадәр;

2.2. планлаштыру проектын һәм линия объектын межалау проектын бастырып чыгару өчен рәсми сайт – http://agryz.tatarstan.ru.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы:

3.1. Әлеге карарны 2019 елның 7 маенда Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3.2. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) Иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3.3. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты административ бинасының беренче катында линия объектын планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча экспозицияне ачу, шулай ук килүчеләр өчен 2019 елның 7 маеннан алып 7 июненә кадәрге чорда экспозиция белән танышу мөмкинлеге булдыру (8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр).

4.4. 2019 елның 7 маеннан 2019 елның 7 июненә кадәрге чорда идентификация үткән кешеләрдән фикер алыша торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итәргә:

- язмача формада түбәндәге адрес буенча: 422230, ТР, Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13, каб. № 17;

- проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: 422230, ТР, Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13, каб. № 17 (8.00 дән 17.00 гә кадәр).

3.5. Проект буенча фикер алышу нәтиҗәләренщ карта җәмәгать фикер алышулары беркетмәсен һәм иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.6. 2019 елның 13 июнендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында, (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.С. Авдеевка йөкләргә.




**В.В. МАКАРОВ**